**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет
Сарлинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района**

ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы, 423315
Тел. 365-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты**

Үзәк урам, 68А,
Сарлы авылы, 423315
Тел. 365-34

---

**КАРАР**
«15» март 2021 ел, №6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыю турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең 2020 елның 12 маендагы №13-20р күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның күпләп ял итүе һәм суда коткару чаралары өчен җиһазландырылган урыннар булмау сәбәпле, су объектларының һәм елгаларының санитария-гигиена нормаларына туры килмәве, елгаларда һәм сулыкларда бәхетсезлек очракларының иминлеген тәэмин итү, кисәтү һәм санын киметү максатыннан Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан су объектларында су коенуны тыярга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең барлык милек рәвешләрендәге предприятие, оешма, учреждениеләр җитәкчеләренә су объектларында су коенуны тыю турындагы әлеге карар белән танышуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетына су объектлары янында су коенуны тыю турындагы мәгълүмат белән кисәтү аншлаглары урнаштырырга.
4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://aznakayevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Башлык М.Р.Шәрипов